Республика Татарстан

**ГЛАВА ЮТАЗИНСКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА**

423950, п.г.т.Уруссу ул.Пушкина, 38
тел.: (85593) 2-80-13
факс: (85593) 2-62-20

Татарстан Республикасы

**ЮТАЗЫ МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ БАШЛЫГЫ**

423950, Урыссу ш.т.б. Пушкин урамы, 38
тел.: (85593) 2-80-13
факс: (85593) 2-62-20

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

**21 ноября 2018 года** **№ 89**

Ютазы мунниипаль районы Советы

муниципаль хезмәткәрләренең этика

һәм хезмәт тәртибе Кодексына

үзгәреш кертү турында

Ютазы муниципаль районы Башлыгыныц 2017 елның 18 сентябрендәге 78 номерлы карары белән расланган Ютазы муниципаль районы Советы муниципаль хезмәткәрләренең этика һәм хезмәт тәртибе Кодексын гамәлдәге законнарга туры китерү максатларында, карар бирәм:

V бүлекнең 4 пунктын яңа редакциядә бәян итәргә:

Муниципаль хезмәт үтү белән бәйле рәвештә муниципаль хезмәткәргә физик һәм юридик затлардан вазыйфаи хәл белән бәйле рәвештә яисә вазыйфаи бурычларны башкару белән бәйле рәвештә акчалата бүләкләр (бүләкләр, акчалата бүләкләр, ссудалар, хезмәт күрсәтүләр, күңел ачу, ял өчен түләүләр, транспорт чыгымнары һәм башка бүләкләр) алу тыела. Муниципаль хезмәткәр тарафыннан беркетмә чаралары, хезмәт командировкалары һәм башка рәсми чаралар белән бәйле рәвештә кабул итеп алынган бүләкләр муниципаль милек дип таныла һәм Россия Федерациясе Гражданнар кодексында билгеләнгән очраклардан тыш, муниципаль хезмәткәр тарафыннан, аларда ул муниципаль хезмәт вазыйфасын биләгән җирле үзидарә органына, муниципаль берәмлекнең сайлау комиссиясенә акт буенча тапшырыла. Беркетмә чарасы, хезмәт командировкасы яки башка

рәсми чаралар белән бәйле рәвештә муниципаль хезмәткәр тарафыннан алынган бүләкне тапшырган муниципаль хезмәткәр, аны Россия Федерациясе норматив хокукый актлары белән билгеләнә торган тәртиптә сатып алырга мөмкин.

Район Башлыгы Р. М. Нуриев

Тюрина С.А.

2-79-27